# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлегенең Балтамак авылы торак пунктында
2022 елда үзара салым кертү турында

**2021 елның 17 ноябре** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлегенең Балтамак авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2022 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге Балтамак авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк затлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 8000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
- Балтамак авылы зираты территориясен койма белән әйләндерү өчен материаллар сатып алу;
- Балтамак авылларында кышын җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту;
- Балтамак авылында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);
- Су башнясы территориясен әйләндереп алу (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Балтамак авылында (Сабантуй, 9 Май, Яңа ел, өлкәннәр көне, Инвалидлар көне) бәйрәмнәр үткәрү өчен бүләкләр алу.

3. Әлеге карарны Рангазар авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Р. Шарипова

Совет Рангазарского сельского поселения
Рангазар авыл җирлеге Советы
ОГРН 1021601313470
ИНН 1636001200